ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.10.2017 Казан ш. № 188

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында" 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында” 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 10 октябрендәге 781 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында" 2015 елның 17 апрелендәге 44 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 01.12.2015 № 157, 07.06.2016 № 49 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктында "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә" сүзләрен өстәргә;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый советның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә формалаштырыла.

3.2. Иҗтимагый совет Дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә үз составында 14 кешенең ирекле катнашуы нигезендә төзелә.

3.3. Дәүләт комитеты Иҗтимагый совет составы расланган көннән соңгы 30 көннән соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын уздыруны оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның рәисе һәм рәис урынбасары сайлана. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан ачык тавыш бирү юлы белән алынган тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турында мәсьәлә Дәүләт комитеты рәисенең мөрәҗәгате, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәис урынбасарының шәхси гаризасы яисә Иҗтимагый совет әгъзалырының гомуми санынннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил итүче күләмдә Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерелә. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан алынган тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен билгеләп куя.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләр чоры Иҗтимагый советның яңадан төзелгән составының беренче утырышы узган көннән соң өч ел тәшкил итә.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Дәүләт комитеты карары нигезендә Иҗтимагый совет рәисенең күрсәтмәсе нигезендә туктатыла, түбәндәге очракларда:

аңа карата Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаеп тагылганда;

аңа карата административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

аны дәүләт хакимияте органының закон чыгару (сайлаулы) депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлаулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле вазыйфасына кандидат буларак теркәгәндә, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кертелгән очракта.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

аның вәкаләтләр чоры беткәндә;

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза тапшыргач;

Иҗтимагый совет эшендә аның сәламәтлеге торышы буенча катнашуга сәләтле булмавы очрагында;

аңа карата чыгарылган гаепләү турындагы суд карары законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул эшкә сәләтсез яки сәбәпсез юк булучы дип танылганда;

аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылганда – Иҗтимагый совет утырышында катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар нигезендә;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (өч мәртәбәдән артык) Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмаганда;

нигезле сәбәпләрсез системалы рәвештә (ике мәртәбәдән артык) Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының боерыкларын үтәмәгәндә;

ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

чит ил дәүләте гражданлыгын алгач (билгеле бер дәүләт гражданлыгын алгач).

Россия Федерациясе гражданлыгы беткәч;

3.9. Иҗтимагый советта әгъза булуны туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы нигезендә яисә Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәис урынбасарының күрсәтмәсе нигезендә кабул ителгән Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына шушы Нигезләмәнең 3.8 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы-уникенче абзацларда каралган хәлләрнең барлыкка килүе турында хәбәр итәргә бурычлы.";

түбәндәге эчтәлекле $5.12^1$ пунктын өстәргә:

"$5.12^1$. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.";

5.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенә оештыру-техника ягыннан булышу Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.".

Рәис С.Е. Иванов